**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 26 декабрь № 987

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында» 2013 ел, 28 февраль, 136 нчы карарына үзгәреш кертү хакында

«Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе филиалларында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында» 2013 ел, 28 февраль, 136 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 29 апрель, 293 нче, 2014 ел, 24 декабрь, 1020 нче, 2016 ел, 2 март, 128 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Учреждение хезмәткәрләренең иң чик штат санын вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең 2 578 686,0 сум күләмендәге айлык фонды белән 600 берәмлек итеп билгеләргә.».

2. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән берлектә, «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесенең оештыру структурасын билгеләнгән тәртиптә билгеләгәннән соң ике ай эчендә, бу карар нигезләмәләрен исәпкә алып, 2017 елга Татарстан Республикасының аерым дәүләт

учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

3. Бу карар 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\987.docx